ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

11.10.2022 — пос. Октябрьский — 04

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогында гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2022 елның 26 октябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрүгә сез ризамы:
- Балалар мәйданчыгын сатып алу һәм Октябрьский поселогында төзекләндерү
«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Октябрьский авыл Мәдәният йорты бинасында Октябрьский бистәсе, Үзәк ур., 7 йорт адресы буенча гражданнар җыенын 17.00 сәгатьтә үткәрергә:

4. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш. Р. Азизов